Россиябез Президенты В.В.Путин яраткан спорт то-ре - дзюдо. Бер караганда бер-берен белән сугышу, коч алышу кешене каты йорәкле, кондәшенне аямаслык хәлгә житкерергә тиеш булса, дзюдо кондәшенә һәм тормышка йомшак булуга онди. Икенче торле аны интеллектуаль, джентельменнар корәше дип тә йортәләр.
Сvзебез шул матур спорт торе белән шогыльләнгән һәм унышлары турында да горурланып сойли алырлык Мязитов Марат улы Ринатнын уллары - Артур, Денис, Рустам турында булыр.
Бvген Россиядә, башка илләрдәге кебек, дзюдо популяр спорт торе. Корәштә кулланган алымнар байлыгы аны аеруча матур итә. Дзюдо фәлсәфәсе - батыр тыныч булырга, кондәшенне хормәт итәргә, тырышлыкка, vз максатына ирешергә ярдәм итә, корәшче холкын тәрбияли.   Үткән ел Федераль Сабантуйда мин корәш белән ат чабышлары турында яздым, шуна башыннан алып азагына кадәр ярышларны карадым. Мавыктыргыч ат чабышлары анлашыла. Тагы татар корәшен карадым, бу аерым тор. Каратэда аяк белән, бокста кул белән сугалар...
Дзюдо ярышларына килеп утырдым - фәлсәфәсен дә, корәш алымнарын да анламыйм икән бит. Спортсменнар бер-беренә ишегалдындагы ике әтәч кебек киләләр дә ябышалар, киләләр дә ябышалар. Сугу дигән әйбер юк монда. Бәлки шунадыр да инде, дзюдода кондәшенә йомшак булырга кушадыр. Дзюдо алымнары белән бераз ирекле корәш (грек-рим корәшенә) охшаган. Баскан килеш кондәшенне аркасы остенә - чалкан яткырсан, я кvтәреп бәрсән - ин зур балл жыясын. Яткыру гына тvгел, әле аны 15-25 секунд дә-вамында яткан килеш тотарга да кирәк, мона тагын берничә балл остәлә. Анламаган ке-шегә бер-берсе остенә ятып торганын карарга кә- мит инде менә! Анлаучылар да бар. Алар инде, ике ян-якта спортчыларга кинәш-ләрен бирvче тренерлардан та катырак кычкырып, vзләренчә «кинәш» биреп тордылар. Башка ярышларда да шулайдыр инде.
Шулай, Саранск шәһәре 35 мәктәпнен 6 сыйныф укучылары Артур, Денис, Рустам, тренерлары Давид Рамазиевич Гвелесиани житәкчелегендә, дзюдо белән ихластан шогыльләнvчеләр турында сvзем: унышлары соендерә. Бvген алар

Мордовия чемпионнары, ә киләчәктә - Россиянен булырга тырышалар. Дvрт ел эчендә (алар шулкадәр вакыт бу спорт торе белән шогыльләнәләр) Саранск, Мәскәv, Ульян, Казан, Воронеж, Пенза, Тvбән Новгород олкәсенен Городец белән Дзержинск шәһәрләрендә, Йошкар-Ола, Чебоксары, Воронеж, Самара, Саратов ярышларында жинvчеләр. Мәсәлән, 2022 елнын 16 октябрендә Сасово шәһәрендә дзюдо буенча vткән ярышларда Мордовиянен А.В.Мишин исемендәге спорт корәше һәм дзюдо мәктәбе спортсменнары да катнашты, шул исәптән Артур, Денис, Руслан Мязитовлар да. Нәтижәләре шатландыра: 1 урын - Мязитов Денис (38 кг), шулай ук 1 урын - Мязитов Артур (42 кг) һәм 2 урын - Мязитов Рустам (38 кг). Бу яшь спортчыларнын һәрвакыт

жинvләр генә тvгел, жинелvләре дә була. Рустам ярышлар турында:
- Доресен генә әйткәндә, ярышларда тамашачы коч биреп торса - бу супер ярдәм! Тотамида ин авыры кондәшенне жинv тvгел, ә vзенне жинv. Монда нәрсә беләсен, шуны кvрсәтергә, бар коченне бирергә кирәк, ә мин булдыра алмадым, икенче урында идем. Кочсезрәк булдым. Ләкин хәзер нәрсә остендә эшләргә икәнен беләм. Шуна да жанатарларымны яна жинvләр белән тагы шатландырырмын дип уйлыйм, - диде яшь спортчы.
Жинv очен кvп тырышырга кирәк. Бvген бар кочләрен Самара шә-һәрендә vтә торган ПФО ярышларында кvрсәтәләр. Без спортчыларнын осталыклары белән сокланабыз, команда һәм шәхси зачетта жинvләрен телибез. Унышлар сезгә! Бу оч игезәк малай спортта да, укуда да vзләрен сынатмыйлар. Укулары да әйбәт бара. Рустамнары физкультура предметы буенча быелгы мәктәп туры олимпиадасында - беренче.
Әйтеп китәргә кирәк, Мязитовлар гаиләләре тату яши. Әтиләре Ринат Марат улы, тумышы белән Ләмберә районы Шербак авылы малае; бvген Саранск шәһәрендәге житәкчеләрнен берсе. Ә әниләре Рәстәм кызы Аделя, шәхси эшмәкәр (индивидуальный предприниматель). Балаларына дорес тәрбия бирергә тырышалар, шуна да алар бар момкинчеләрне эшкә жигәләр.

Наилә НАСЫРОВА